**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

№ 6

18.09.2018ел

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1.Җирле референдум үткәрү инициативасы:

"2019 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:

***1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге***

***2. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:***

***3.Күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:***
***- фонарьлар сатып алу һәм урнаштыру***

***4. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру***

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы Ф.Н.Степанов